| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БАЛТАСИНСКОГО<br>ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАЛТАСИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>БАЛТАЧ ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«28» август 2025 ел № 182

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге башкарма комитетының 2018 елның 12 декабрендәге 81 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында (01.03.2023елгы үзгәрешләр белән) «Чүп-чарны, үләнне, яфракларны һәм башка калдыкларны, материалларны яндыру урыннарын һәм ысулларын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 03.02.2025 еладагы 90 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге Башкарма комитетының 2018 елның 12 декабрендәге 81 номерлы(01.03.2023г номерлы үзгәрешләр белән) "Чүп, үлән, яфрак һәм башка калдыкларны, материалларны яндыру урыннарын һәм ысулларын билгеләү турында" карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

- 1.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Торак пунктларның гомуми кулланылыштагы җирләрендә, шулай ук торак пунктлар территорияләрендә урнашкан хосусый йорт биләмәләрендә азык әзерләү өчен ачык ут куллану, шулай ук чүп-чар, үлән, яфрак һәм башка калдыкларны, махсус билгеләнгән һәм җиһазландырылган урыннан тыш материаллар яисә эшләнмәләр яндыру тыела.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырырга, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (baltasi.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Балтач шәһәр җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе И.Д.Габдрахманов